**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2026елның 09 апреле** **13 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 нчы номерлы Указының 4 нче пунктына ярашлы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Үз көчен югалткан дип танырга:

1)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү Тәртибен раслау турында»гы 19 нчы номерлы карарын.

2) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2022 елның 4 апрелендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү Тәртибен раслау турында”гы Сокуры авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге 19 нчы номерлы карарына үзгәрешләр һәм тулыландырулар кертү турында»гы 08 нче номерлы карарын;

3)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2023 елның 16 гыйнварындагы «Сокуры авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 декабрендәге “Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тәкъдим итүе, шулай ук Лаеш муниципаль

районы Сокуры авыл җирлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тәкъдим итүе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 111 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 01 нче номерлы карарын;

4)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 декабрендәге «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, Сокуры авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәүләрен тикшерү турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 113 нче номерлы карарын.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Р.Мәүлиев**